# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**“Физик культура һәм спорт турында”
Татарстан Республикасы Законының 6 һәм 12 статьяларына үзгәрешләр
кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 9 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

“Физик культура һәм спорт турында” 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 10 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяның 2 өлешенә түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пункт өстәргә:
“$1^1$) физик культура һәм спорт өлкәсендә дәүләт сәясәтен уздыруда катнашырга;”;

2) 12 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“1. Физкультура чараларын яки спорт чараларын оештыручылар аларны үткәрү шартларын, шул исәптән спорт судьяларына спорт ярышларында катнашу өчен алар тарафыннан алына торган азык-төлек, спорт җайланмасы, җиһазы, спорт һәм парад формасы хакын түләүгә бәйле компенсация түләүләрен бирү шартларын һәм тәртибен, билгеләүләр, мондый чараларны оештыру һәм үткәрү өчен җаваплы булалар, мондый чараларны туктатып торырга һәм туктатырга, аларны үткәрү вакытын үзгәртергә һәм аларның йомгакларын расларга хокуклылар.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2010 елның 29 июне
№ 40-ТРЗ